**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

К А Р А Р

**№ 24** **Бәйрәкәтамак ав.** **30.11.2018 ел**

**Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2014 елның 21 ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 23 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 маддәсендәге 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге «Физик затлар милкенә салым турында"гы 23 санлы карарына (2015 елның 15 октябрендәге 8 санлы, 2018 елның 1 июнендәге 11 санлы карары нигезендә) түбәндәге өстәмәләр:

Түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«3.1 физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә җитмәгән инвалид балалары булган гражданнарны;

2) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалы аз керемле гаиләләрдән булган гражданнарны.

Ел саен салым органнарына раслаучы документлар биргәндә азат итү бирелә.»

2. Әлеге карар административ бинаның мәгълүмат стендында рәсми рәвештә игълан ителгәннән һәм http://jutaza.tatar.ru электрон адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылганнан соң үз көченә керә, Россия Федерациясе Салым кодексының I өлешендәге 5 маддәсенең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әһлиева